РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» март 2023 ел г. Альметьевск № 644

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Көнкүреш характеристикасы бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 20 октябрендәге 1202 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР ИТӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Көнкүреш характеристикасы бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 20 октябрендәге 1202 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 12 июлендәге 1529 номерлы, 2022 елның 4 маендагы 821 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

5 бүлектә:

5.1 пунктның 3 пунктчасында «каралмаган документлар» сүзләрен «документлар яисә мәгълүмат бирү яисә гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне башкару» сүзләренә алмаштырырга.»;

5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8, 9, 10 пунктлар өстәргә:

«8) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәк хезмәткәре, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелгән очракта, күпфункцияле үзәк, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата, мөрәҗәгать итүче тарафыннан "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3

23 111

Зак. № 305-2000

өлешендә билгеләнгән тәртиптә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә, бердәм гариза бирү юлы белән, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин.;

10) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә документлар яисә мәгълүмат бирелгәндә мөрәҗәгать итүчедән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда, моңа «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклар керми.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.10, 5.11 пунктлар өстәргә:

«5.10. Шикаятьне канәгатьләнергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк йә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклары өчен гафу үтенүләр китерә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга тиешле алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.;

5.11. Шикаятьне канәгатьләндерелмәгән дип таныган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов